МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.06.2020 г.Казань № 494

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 4 августында 6789 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 18 декабрендәге 995 номерлы «Хезмәт ветераны» исемен бирү һәм «Хезмәт ветераны» таныклыгын, «Хезмәт ветераны» таныклыгының дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган «Хезмәт ветераны» исемен бирү һәм «Хезмәт ветераны» таныклыгын, «Хезмәт ветераны» таныклыгының дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Хезмәт ветераны» исеме бирү һәм «Хезмәт ветераны» таныклыгы бирү, «Хезмәт ветераны» таныклыгының дубликаты бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатында, б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт ветераны» исеме бирү һәм «Хезмәт ветераны» таныклыгы бирү, «Хезмәт ветераны» таныклыгының дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау

турында» 2012 елның 18 декабрендәге 955 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 ел № 317, 30.09.2016 ел № 560, 08.06.2017 ел № 348, 13.12.2017 ел № 872, 07.05.2018 ел № 347, 19.09.2018 ел № 892, 24.06.2019 ел № 495, 11.11.2019 ел № 981, 06.04.2020 ел № 228 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Хезмәт ветераны» исеме бирү һәм «Хезмәт ветераны» таныклыгы бирү, «Хезмәт ветераны» таныклыгының дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына китерелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр вазыйфасын башкаручы Р.Ф. Валиуллов

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 10 июлендәге 494 номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 18 декабрендәге 995 номерлы «Хезмәт ветераны» исемен бирү һәм «Хезмәт ветераны» таныклыгын, «Хезмәт ветераны» таныклыгының дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган «Хезмәт ветераны» исемен бирү һәм «Хезмәт ветераны» таныклыгын, «Хезмәт ветераны» таныклыгының дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелгән үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.4.2 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның рәсми сайтында - http://mtsz.tatarstan.ru. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) «Интернет» челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә булдырылган» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында булдырылган» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.2 пунктының «Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «33-ТРЗ номерлы Закон» сүзләрен «2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм

шартлары турында» Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 33-ТРЗ номерлы Закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы 5 пунктның ундүртенче абзацында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктның «Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» графасында «Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)» сүзләренә алмаштырырга.